ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№14** **«04 » август 2015 ел**

Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының
2015 елның 5 мартындагы
5 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ санлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында»гы ПУ-308 санлы Указы нигезендә һәм коррупциягә каршы тору эшчәнлеген камилләштерү максатларында Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл жирлеге башкарма комитетының 2015 елның 27 февралендәге «Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 8 санлы 2015 елның 27 февралендәге «Муниципаль хезмәткәрләр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы 8 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) исемдә, преамбулада, 1 пунктта «гражданнар билгеләгәндә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) муниципаль хезмәткәрләр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге исемлегендә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл
җирлеге башлыгы: И.М.Миңнеханов